ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясына үзгәреш кертү хакында» 187-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясына үзгәреш кертү хакында» 187-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы

М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 22 июле
№ 670-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 26 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 72 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2026, № 1 (I өлеш), «2027 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2028 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Җирле үзидарә органнарына һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларына карата контроль-күзәтчелек эшчәнлеген оештыру турында һәм «Бердәм гавами хакимият системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 9 апрелендәге 85-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Бердәм гавами хакимият системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелде, алар белән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кагылышлы нигезләмәләренең гамәлдә булу срогын 2028 елның 1 гыйнварына кадәр озайтылды (элек бу нигезләмәләр 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалтачак дип каралган иде).

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 26 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 66 статьясы белән «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга сылтаманы «Бердәм гавами хакимият системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законга сылтамага алмаштыру өлешендә үзгәрешләр кертелде.

Үзгәртелә торган нигезләмәләр җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кагылганлыктан, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 26 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 72 статьясындагы 2 өлешендә әлеге нигезләмәләр 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керәчәк дип каралган иде (элек федераль законнарда каралган кебек).

Федераль законнардагы югарыда әйтелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, әлеге датаны 2028 елның 1 гыйнварына дип үзгәртергә кирәк.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тану, туктатып тору, үзгәртү яисә кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.